Мәмәшир авыл җирлеге

КАРАР

31 июль, 2024 ел № 21

Мәмәшир авыл җирлеге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Мәмәшир авыл җирлеге Уставы нигезендә Мәмәшир авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Мәмәшир авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Кукмара муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Мәмәшир авыл җирлеге Башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында Мәмәшир авыл җирлеге Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

http://kukmor.tatarstan.ru2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мәмәшир авыл җирлеге Советы социаль экономик һәм финанс даими комиссиясенә йөкләргә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1061607753012
ИНН 1623001702